КАЛӘМНЕҢ КАДЕРЛЕСЕ
Журналистлар арасында «Бәллүр каләм» бәйгесе җиңүчеләре билгеле

> 2

ҮРНӘК БАЛАЛАР
Кайсы – иң яшь бизнесмен, кайсы – иң яшь китап укучы

> 3

ИЛДАР МАТУРОВ:
«Патриотизм тарихи хәтер аша формалаша»

> 3

ҖЫР БӘЙРӘМЕ
Мәдәни вакыйганың төп үзенчәлеге нидә?

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 76 (29043) | Чәршәмбе | 31 май | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Эльвира ВӘЛИЕВА

ТЫРЫШКАН ТАБА

Үзмәшгульлек

234 мең кеше. Узган ел нәтиҗәләренә караганда, Татарстанда әнә шулкадәр үзмәшгуль теркәлгән. Бу – алдагы ел белән чагыштырганда 40 процентка диярлек күбрәк. Былтыр үзмәшгульләр 31,4 миллиард сум керем алган.

Таңсылу Галимова

Айгөл Камилова ун елга якын милли кул эшләнмәләре ясау белән шөгыльләнә.

Светлана Туганова – Татарстанда теркәлгән үзмәшгульләрнең берсе. Аның кәсебе дә бик үзенчәлекле. Күп еллардан бирле башкаладагы банкларның берсендә җитәкче вазыйфасын башкаручы ханым буш вакытында сәйләннән сумкалар үрә.

– Бу – минем күңел эшем, – ди ул. – Хатын-кызларга матур ташлардан затлы сумкалар ясыйм. Онлайн кибетләрем бар, заказга да эшлим. Мәсәлән, минем кул эшләнмәләрем арасында бәллүр сәйләннән үрелгән сумка бар. Аның авырлыгы – 600 грамм, бәясе – 5700 сум. Мондый сумкага кәрәзле телефон, ачкыч, иннек сыя. Интернетта бәллүр сумкалар 8–9 мең сумнан башлана. Сәйләнне интернеттан заказ биреп алам. Бер сумка ясарга якынча өч көн вакыт кирәк. Мин – һөнәрем буенча икътисадчы. 2021 елның җәеннән бирле үзмәшгуль буларак та теркәлдем. Һөнәри керемгә салым түләүчеләргә дәүләттән бирелгән ярдәм чараларыннан тыш, безгә Казанда узучы ярминкәләрдә бушлай катнашу мөмкинлеген дә бирәләр. Мондый чараларга автобуслар белән туристларны алып киләләр. Шуңа күрә ярминкәләрдә яхшы гына акча эшләп тә була.

Хәтерләсәгез, үзмәшгульләргә тәҗрибә рәвешендәге махсус салым режимы 2019 елда илнең дүрт төбәгендә, шул исәптән Татарстанда гамәлгә керде. Беренче мәлдә халыкта кызыксынудан бигрәк борчылу уятты ул. Болай да аз булган керем, махсус салым кертелгәч, күтәрәмгә калачак, дип хафага төште өйдә акчага торт пешерү, пилмән бөгү, оекбаш бәйләү белән шөгыльләнүчеләр. Тик болай эшләүнең уңай яклары да күп булуы ачыкланды. Тәҗрибә рәвешендәге эшне 2020 елның 1 гыйнварыннан илнең тагын берничә төбәгендә, ә соңрак ил күләмендә дә җәелдерделәр. Хәзер үзмәшгуль булып Белоруссия, Әрмәнстан, Казахстан, Кыргызстан гражданнары да эшли ала.

> **!** Эшләүдән, хезмәт күрсәтүдән, товар сатудан кергән акчадан үзмәшгуль буларак теркәлгән физик затлар – 4, шәхси эшмәкәрләр һәм юридик затлар 6 процент күләмендә салым түли. Әлеге төр эшчәнлеккә күчүчеләр керем өчен түләнүче 13 процент күләмендәге салымнан азат ителә. Аларга төрле ярдәм чаралары каралган. Үзмәшгуль буларак теркәлү өчен «Минем салым» мобиль кушымтасы да җитә.

– Үзмәшгульләр институтын үстерү – өстенлекле юнәлешләрнең берсе, – ди икътисад белгече Илдус Сафиуллин. – Ник дисәң, бүген үзмәшгуль буларак теркәлгән кеше иртәгә эшмәкәр дәрәҗәсенә үсеп җитәргә, бюджетка салым түләүләрен арттырырга, яңа эш урыннары булдырырга мөмкин.

> **Сан**
>
> Рәсми мәгълүматларга караганда, һөнәри керемгә салым рәвешендә республика бюджетына **2020** елда – **265,8** миллион сум, **2021** елда – **960,6** миллион сум, **2022** елда – **1** миллиард **497** миллион сум, ә агымдагы елның беренче өч аенда **453** миллион сум акча күчкән.

Саннар үзләре сөйли. Салым федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсеннән алынган мәгълүматларга караганда, 2020 елда һөнәри керемгә салымны 102 мең кеше түләсә, 2021 елда әлеге сан – 169 мең, 2022 елда исә 234 меңне тәшкил иткән. Елдан-ел аларның керемнәре дә арта. Мәсәлән, 2020 елда һөнәри керемгә салым түләүчеләр 12,6 миллиард сум акча эшләсә, былтыр 34,1 миллиард сум керем алганнар.

Үзмәшгуль Ирина Лукоянова гомумән дә тиңе булмаган эшләнмә уйлап тапкан әнә. Ул гүзәл затларга милли бизәкле баш киеме (кокошник) тегә.

– Милли орнаментлар төшерелгән мондый баш киемнәре Татарстанда гына түгел, ил күләмендә дә юк, – дип сөйләде үзмәшгуль «ВТ» хәбәрчесенә. – Белемем буенча мин – икътисадчы. Әмма берничә елдан бирле үзмәшгуль буларак эшлим. Тегү, чигүне күбрәк яратам. Моңа укымадым. Эш башларга мәктәптә өйрәткән белем дә җитә дип саныйм. Бүген нәкъ менә милли орнаментлы эшләнмәләргә сорау зур. Баштарак кокошникларны кулдан чәчәкләр чигеп ясый идем. Танышларым милли бизәк төшереп карарга тәкъдим итте. Шулай эшләдем дә. Бүген мондый баш киемнәрен бик яратып сатып алалар. Күбрәк туристлар кызыга. Милли орнаментларны тарихи чыганаклардан өйрәнәм. Бизәкле кепка, кырлы эшләпә, балаларга резин тасмалы яулыклар сатам. Татарстанда яшәсәк тә, тегү өчен милли орнаментлы чимал табу бик катлаулы. Ул бездә юк дәрәҗәсендә. Республикадагы җитештерүчеләрдән кат-кат сорадым. «Бу отышлы түгел», – диләр. Балаларга милли бизәк төшерелгән резин тасмалы яулыкны, мәсәлән, 400 сумга сатам. Аның тукымасын шәхсән үзем эшләттем. Иң элек дизайнер белән бизәген уйлап таптык, аннары тукымага заказ бирдем. Башта Санкт-Петербург шәһәрендәге бер фабрика тукымага бизәк төшереп бирергә ризалашкан иде. Тик соңрак андый оешманы Казанда да таптым. Кыскасы, миллилек алтын бәясенә төшә. Тик зарланып әйтүем түгел, тырышкан таба ул!

Киләсе елга арта

2030 елга илебездә хезмәткә түләүнең минималь күләме (МРОТ) яшәү минимумыннан артачак. Россия хезмәт һәм социаль яклау министры Антон Котяков әйтүенчә, МРОТны яшәү минимумыннан югарырак темпта арттыру күздә тотыла.

Киләсе елның 1 гыйнварыннан МРОТ күләме 19242 сумга җитәчәк.

Сүз уңаеннан, Дәүләт Думасында автомобильчеләр өчен штрафларны МРОТ күләменә бәйле рәвештә билгеләүне тәкъдим иткәннәр.

Саклангнны саклар

Быел 4 ай эчендә Татарстан юлларында 65 кешенең гомере өзелгән. Узган елның шушы ук чорындагыга караганда 20 кешегә (23,5 процентка) кимрәк күрсәткеч бу. Эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ идарәсе җитәкчесе Рөстәм Гарипов әйтүенчә, һәлак булучылар саны кимесә дә, аварияләр (узган елның шушы ук чорында – 858, быел – 911) һәм зыян күрүчеләр (1076дан 1130 кешегә җиткән) арткан.

Юлларда һәлак булган 65 кеше арасыннан 29ы – йөртүче, 23е – пассажир, 13е – җәяүле. 14 районда аварияләр саны кимегән, 19 районда һәлак булучылар юк.

Әгерҗе, Актаныш, Алексеевск, Зәй, Биектау кебек районнарда (барлыгы 13 район) һәлак булучылар саны арткан. Аның әйтүенчә, юлларда торак пунктлардан читтә һәлак булучылар (60%, ягъни 65 кешенең 39ы) күбрәк теркәлгән. Калган 26 кешенең гомере торак пунктлар эчендә өзелгән. Гомумән, авыл-бистәләрдә аварияләр саны – 9 процентка диярлек, һәлак булучылар – 18 процентка, җәрәхәтләнү-имгәнүчеләр саны 10 процентка диярлек арткан.

Укытучы коткара

Дәүләт Думасы мәктәпләрдә укытучыларның балаларга беренче медицина ярдәме күрсәтү хокукы турында закон кабул иткән. Думаның Мәгърифәт комитеты рәисе беренче урынбасары Алена Аршинова басым ясап әйткәнчә, укытучылар, бик кирәк булган очракларда, «ашыгыч ярдәм» килгәнче, беренче медицина ярдәме күрсәтә алачак. «Бу хакта фикер алышулар, парламент тыңлаулары үткәрдек. Медицина оешмалары гына түгел, бәлки мәгариф оешмалары да балалар сәламәтлеген саклау буенча эшләргә тиеш булачак», – дигән депутат.

Моннан тыш укучыларны физкультура һәм спорт дәресләренә кертүнең аерым тәртибе күздә тотыла. Укучыга белем алу өчен аерым шартлар кирәк булганда, ата-анага баласының сәламәтлеге турында мәктәп хезмәткәрләренә хәбәр итү бурычы куела.

Кимесә дә, бетмәгән

Татарстанда бер атна эчендә (22–28 май) 133 кешенең коронавирус иярткүе ачыкланган. Инфекциягә каршы көрәшү буенча федераль оператив штаб хәбәренә караганда, пандемия башланганнан бирле республикада COVID-19 йоктыруның 205886 очрагы теркәлгән.

Узган атнада 42 кеше республика хастаханәләренә салынган. Шушы вакыт эчендә – 180, пандемия башланганнан бирле 203525 кеше савыккан. Барлыгы 2010 кеше вафат булган. Соңгы 7 көндә үлем-китем очраклары теркәлмәгән.

Россия буенча бер атна эчендә 13655 кеше чирләгән. 2964 кеше хастаханәгә озатылган. Пандемия башланганнан бирле илдә коронавирус йоктыруның 22929149 очрагы ачыкланган. Шушы чорда җәмгысы 399057 сырхау инфекциядән вафат булган. Узган атнада коронавирус 164 кешенең гомерен өзгән.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Борчыган мәсьәлә

Сыйфатсыз киштә

Бер ел эчендә Россиядәге азык-төлек кибетләрендә хокук бозу очраклары 10 тапкыр (!) арткан. Дәүләт прокуратурасы тарафыннан уздырылган тикшерү нәтиҗәләре шул хакта сөйли. Хокук бозу очраклары дигәндә, кибетләрдә яраклылык вакыты чыккан азык-төлек сатылу, аларның дөрес сакланмавы күздә тотыла.

Мондый рухтагы иң күп кагыйдә бозу очраклары «Светофор», «Красное & Белое» кибетләрендә теркәлгән. Икенче урында – «Ашан» белән «Лента» супермаркетлары. «Кара исемлек»нең беренче өчлеген исә «Магнит», «Перекресток» кибетләре йомгаклый.

Билгеле булганча, узган елның мартында Россиядә эшмәкәрләрне тикшерү тәртибе үзгәрде. Аларның эшчәнлеген тикшерүгә мораторий кертелде. «Иҗтимагый куллану инициативасы» вәкилләре фикеренчә, сәүдә челтәрләрендә кагыйдә бозу очракларының шул дәрәҗәдә артуына, нигездә, әнә шул үзгәреш сәбәп булган. Шуңа күрә бер ел элек кертелгән мораторийны өлешчә бетереп, планлы тикшерүләрне кире кайтарырга тәкъдим итә алар.

– Роспотребнадзор идарәсе белгечләре, кибеткә килеп, кагыйдә бозуны терки дә кисәтү ясый. Шуның белән шул. Элегрәк моның өчен штраф язалар, товарны сатудан алып, кибетне ябарга ук мөмкиннәр иде. Хәзер әнә шулай кисәтү белән генә чикләнәләр. Нәтиҗәдә эре сәүдә челтәрләрендә тәртип ягы аксый башлады, – диелә алар әзерләгән мөрәҗәгатьтә.

Өйгә кайткач, сатып алынган товарның бозылган икәнлеге ачыкланса, ни эшләргә соң? Юрист Илнур Галиуллин сүзләренә караганда, «Кулланучылар хокукын яклау турында» законның 18 нче маддәсе нигезендә, кибеттән алынган товар кулланылышка яраксыз булып чыкса, кеше аны шундый ук, әмма сыйфатлы товарга алмаштыруларын; аны шул ук, әмма икенче маркалы товарга алмаштыруларын; товарны сатучыга кире биреп, түләнгән акчаны кире кайтаруларын таләп итә ала.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Товарның кабы ачылган яки аның бераз кабып каралган булуы «брак» товарны кире алмаска сәбәп була алмый. Товарның бозылганын, яраксыз икәнен дәлилләгән очракта аны кире алырга теләмәсәләр, ике нөсхәдә шикаять язарга кирәк. Кибеттә сезнең шикаятьне кабул итүдән баш тартсалар, оешмага аны почта аша юллагыз. Алар сезгә язмача җавап бирергә тиеш булачак. Моннан тыш Роспотребнадзор идарәсенә мөрәҗәгать итеп, сыйфатсыз товарны экспертизага да тапшыра аласыз, – ди ул.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Сүзгә-сүз

Вячеслав ВОЛОДИН, Россия Дәүләт Думасы Рәисе:

Июнь аенда махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаиләләренә ярдәм итүгә юнәлдерелгән яңа нормалар эшли башлаячак. Безнең яклаучыларыбыз үзләренә тиешле барлык ярдәмне алачакларына, ә гаиләләре мохтаҗлык кичермәячәгенә ышанырга тиеш.

(Telegram-каналыннан)

ТАТАРСТАНДА – БАЛАЛАР ЯЛЫ

Быел балалар сәламәтләндерү лагерьларында Татарстанда яшәүче 44 мең балигъ булмаган бала ял итәчәк.

146 мәктәп яны лагере

2 палаткалы лагерь

27 шәһәр читендәге лагерь



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ГАЗ: АЛУЧЫ ТҮГЕЛ, САТУЧЫ ТҮЛИ

Глобаль икътисад караңгылык зонасына керүен дәвам итә. Бу локаль конфликтларның үсүенә китерә. Кытай икътисадыннан күңелсез сигналлар ишетелә. Чин хакимиятләре апрель аеннан башлап ковид белән авыручылар саны артуын әйтә.

Без инде коронавирусның куркыныч булуын онытып бетердек. Кырыс карантин шартларында озак вакытлар бикләнеп яшәгән чиннар аннан әле һаман да курка. Бу юлы инде түрәләр халыкны өйләрдә бикләргә, подъезд ишекләрен эретеп ябыштырырга җыенмый. Пандемиягә каршы карантинның файдасыз булуын төшенделәр. Вакциналаштыру да, күрәсең, нәтиҗәсез. Нәтиҗәсе булса, Кытай, планета белән бераякка атлап, ковид турында онытыр иде. Хәзер чиннарга бернинди дә чикләүләр кертмичә, чирне бар илләрдән дә җиңелрәк үткәргән швед моделенә күчәргә туры килә. Чир йоктыру нәтиҗәсендә барлыкка килгән табигый иммунитет – күрәсең, иң яхшы чарадыр. Кытайда чирләүчеләр саны арту безгә турыдан-туры диярлек килеп кагыла. Чин икътисады үсеш темпларын акрынайта. Кучемсез милек сату апрельдә 2019 елның 63 процентына кадәр түбәнәйгән. Май аенда яшьләр арасында эшсезлек 20,4 процентка җиткән. Пекинда вуз дипломы алган яшьләрне эшкә авылга барырга өндиләр. Кытай икътисадындагы проблемалар чимал товарларына бәяне төшерә: бакыр һәм тимер рудасы очсызлана. Россия резервларның төп валютасына әйләнә башлаган юань бәясен югалта.

Европада зәңгәр ягулык бәясе кискен түбәнгә китте. Белгечләр әйтүенчә, вазгыять шул дәрәҗәдә кискенләшергә мөмкин: берара газ өчен кулланучыларга түгел, сатучыларга түләргә туры килмәгәе. 2020 елгы нефть җиһады вакытында андый вазгыять «кара алтын»га бәйле рәвештә туган иде. Газ очсызлануның берничә сәбәбе бар. Европада газ саклагычлар рекордлы рәвештә тулы. Кышның җылы килүе газга ихтыяҗны киметте, саклагычлардагы газ бик аз тотылды. Кризис нәтиҗәсендә энергия чыганакларына сорау кимеде. Европаның иң көчле икътисады – Германия техник рецессия хәлендә. Башка икътисадларда да хәл шуңа таба бара. Кояш, җил энергиясен файдалану арта. Сәнәгать предприятиеләре, бәясе төшүгә карамастан, зәңгәр ягулык сатып алуны арттырмыйлар. Бу – кризисның бер билгесе.

Икътисадның тупикка кереп баруы дәүләтара һәм милли конфликтлар санын арттыра. Халыкның игътибарын читкә юнәлтүнең сыналган ысулы бу. Европа үзәгендәге Косовода хәл яңадан кискенләште. Апрельдә анда муниципаль сайлаулар булып узган иде. Серблар сайлауга бойкот белдереп катнашмадылар, нәтиҗәдә шәһәр мэрлары булып албаннар сайланды. Серблар сайланган мэрларны административ биналарга кертмичә, аларны бикләделәр. Протестлар НАТО көчләре белән бәрелешкә кадәр үсте. Төбәктәге халыкара KFOR көчләренең 41 сугышчысы зыян күрде, авыр хәлдәгеләр бар. Сербия Президенты Вучич: «Приштина серблары НАТО белән бәрелештерергә тели», – дигән белдерү ясады. Ике ил арасында хәрби конфликт куркынычы яңадан үсә.

Россиядә

АКЧА ГЫНА ҖИТМИ

Россиянең эчке тормышында да чишелешен тапмаган катлаулы мәсьәләләр өсте-өстенә өелә. Демография буенча илкүләм проект көтелгән нәтиҗәләрне бирми, түрәләр теле белән әйтсәк, «кире үсеш» күзәтелә. Гади телгә күчерсәк, туучылар саны зур темплар белән кими.

Хезмәт һәм социаль яклау министры урынбасары Ольга Баталина соңгы алты елда беренче балалар тууының суммар коэффициенты 19,9 процентка, икенче балаларныкы 31 процентка кимүен әйтә. Әлеге саннарга карап, демографик упкынның масштабын чамалау кыен түгел. Кризисның сәбәпләре күптөрле. Төп сәбәп: Россия күпме генә үзен Көнбатышка каршы позициягә куярга тырышмасын, нигездә бездә дә бер үк глобаль идеология тантана итә. Көнбатыш идеологиясе хакимлек иткән бар илләрдә дә демографик кризис кискен.

Белгечләр тагын бер мәсьәләдә чаң кагалар. Илдә кеше капиталының сыйфаты начарая. Кешеләр сәламәтлеккә туймый, белем бирү сыйфаты түбән, профессиональ күнекмәләр мактанырлык түгел. Бюджетта акча ташып торган елларда оптимальләштерү белән мавыгу, күкрәп, үзенең кайтавазын бирә, димәк. Ябылган хастаханәләр һәм мәктәпләр рәнҗеше төшә җәмгыятькә. Белгечләр, әлегә икътисад шул сәбәпле тулай эчке продукт 0,5 проценттан артык югалта, диләр. Эшче көчләрнең сыйфаты түбәнәю сәбәпле, югалтуларның артачагын да фаразлыйлар. Махсус хәрби операция фонында квалификацияле кадрларның читкә агылуы да каты китереп суга. Әйе, әйе, Россиядә Мәгариф, Сәламәтлек саклау, җитештерүчәнлекне арттыруга бәйле илкүләм проектлар да бар. Алар өчен байтак акча да бүленә. Әмма нәтиҗәгә ирешү җиңел бирелми.

Хисап палатасы яңа гына социаль контрактның нәтиҗәлелеге турында игълан итте. Искә төшерик: социаль контракт – дәүләт белән кереме яшәү минимумыннан түбән булган гражданин арасындагы субсидия бирү турындагы килешү ул. Килешү дүрт юнәлеш буенча төзелә ала: эш эзләү (яңа квалификация алу өчен уку да шуңа керә), шәхси эшмәкәрлек, шәхси хуҗалык алып бару, авыр тормыш шартларыннан чыгу. Дәүләт акча бирә, гражданин исә, дәүләт таләп иткәннәрнәрне тормышка ашырып, фәкыйрьлектән котыла. 2021 елдан башлап мондый механизм 84 төбәктә гамәлдә. 2021–2022 елларда программа өчен 63,2 миллиард сум акча (51,6 миллиарды федераль бюджеттан) тотылган. 558 меңнән артык социаль контракт төзелгән.

Аудиторлар нәтиҗә ясый: социаль контракт фәкыйрьлектән котылуга уңай нәтиҗә ясый. 2021 елда анда катнашучыларның 52,5 процентының кереме арткан, 2022 елда – 66 процентныкы. «Әмма, – диләр белгечләр, – социаль контракт фәкыйрьлектән коткаруын коткара, ләкин түбән хезмәт хакы алып эшләүгә китерә». Кешеләр бик тыйнак керем чыганагына гына ирешәләр.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

ЯЛ ИТКӘЧ, КУБОК ОТАРГА ЯРЫЙ

«Җиңүгә омтылыш үрнәген күрсәттегез». Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов «Ак барс» хоккей командасы уенчылары һәм тренерлары белән очрашуда егетләрне шулай дип мактады. Очрашу узган елгы сезон нәтиҗәләренә багышланган иде.

– Сез холкыгызны һәм җиңүгә омтылышыгызны күрсәттегез. Сезонның икенче өлешендә мавыктыргыч хоккей күрсәтеп, Көнчыгыш конференциянең беренче урыныннан турнирның хәлиткеч этабына эләгүегез шуның нигезе булып тора, – диде Рөстәм Миңнеханов, спортчыларга мөрәҗәгать итеп.

«Ак барс» клубының узган сезондагы юлы җиңелләрдән булмады. «Нефтехимик» һәм «Адмирал» командалары белән алтышар уен уйналды, финалда исә көчле көндәш – «Авангард» көтә иде. Узган җиңелүләр өчен реванш алу максаты да торды.

– Без көткән финал килеп җитте. Мәскәүнең «ЦСКА»сы безнең көндәшебез булды. Җиде хәлиткеч матч узды. Финалда барысын да күрдек: җиңү шатлыгын да, җиңелү күз яшьләрен дә... Көмеш медаль яулый алуыгыз җанатарлар йөрәгенә өмет очкыны салды, – диде Рөстәм Миңнеханов. Киләсе елга Гагарин Кубогының кабат Татарстан командасыныкы булуына өметен дә җиткерде.

Рәис команданың уңышлы чыгышында тренерларның һәм команда җитәкчелегенең өлеше дә булуын искәртте. Гаилә, җанатарлар, Татарстан халкының ышанычы, клубка булган хөрмәте дә моңа керә.

«Ак барс» командасының баш тренеры Зиннәтулла Билалетдинов та Рәискә рәхмәт сүзләрен җиткерде: «Команданың уңышларын күзәтәсез, мөмкинлекләр тудырасыз. Без моны күрәбез, таяныч тоябыз. Лаеклы уен күрсәтү өчен барысын да эшләдек».



tatarstan.ru

Уенчылар да Рәис янына буш кул белән килмәгән булып чыкты. Алар аңа «Ак барс» хоккей клубы уенчыларының автографлары куелган панно һәм Россия Хоккей федерациясенең көмеш медален тапшырды.

Билалетдинов командада калырмы? Очрашуда да бу сорау күтәрелде. Уңай җавапны бөтен республика көтә бугай. Зиннәтулла Билалетдинов исә сорауга: «Һәр нәрсәнең – үз вакыты», – дип кенә җавап биргән. Шул вакытны көтәбез!

Ышаныч кирәк

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Мәскәүгә эшлекле сәфәре барышында Дума Рәисе Вячеслав Володин белән очрашты, шулай ук Россия парламентының Түбәнге палатасында «История рождения» фотокүргәзмәсен ачуда катнашты, Татарстаннан сайланган Дума депутатлары һәм фракцияләр җитәкчеләре белән аралашты.

«История рождения» күргәзмәсе Халыкара балаларны яклау көненә багышлап ачылган. Ул Татарстан фоторәссамы Диләрә Эстрина хезмәтләреннән тора.

«Әлеге күргәзмә билгеле бер дәрәҗәдә дөньяның җиде могҗизасы турындагы мәгълүм фикерне кире кага. Ник дигәндә, иң мөһим могҗиза – кеше. Ә кеше туу – могҗизаның могҗизасы, – ди Думаның Гаилә, хатын-кызлар һәм балалар комитеты рәисе Нина Останина. – Бүген илебездә гаилә һәм балаларга ярдәм итүгә юнәлдерелгән бик күп чаралар күрелә. Әмма бернинди законнар һәм карарлар белән дә яшьләрнең әти-әнигә әйләнүләренә этәргеч биреп булмый. Моның өчен дәүләткә һәм хакимияткә ышану кирәк. Бу мәсьәләдә Татарстан кебек төбәкләрнең тәҗрибәсе бәһаләп бетергесез зур».

Күргәзмә кунакларын республика җитәкчелеге исеменнән Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин сәламләде. «Демографик вазгыятьнең начараюы, гаилә институтын саклау һәм ныгыту – бүген төбәкләрне борчып килгән мәсьәләләр, – дип билгеләп үткән парламент башлыгы. – Гаилә һәм балалар – безнең төп кыйммәтләребез. Ә балалар – үз чиратында, гаиләне ныгытучылар».

«История рождения» – бала туу мизгелләре турындагы фотопроект Татарстанда 2018 елдан бирле гамәлгә ашырылып килә. Дөньяга килүе чагылдырылган тәүге балага инде 5 яшь тулган.

Күргәзмәгә куелган барлык хезмәтләр Чаллы шәһәренең Кама балалар медицина үзәгендә төшерелгән. Аларның авторы – автомобиль төзүчеләр шәһәрендә яшәүче 2 бала анасы Диләрә Эстрина.

Күргәзмә белән танышканнан соң, Фәрит Мөхәммәтшин белән Дума Рәисе Вячеслав Володин төбәкләр законнарын федераль законнарга туры китерү һәм илнең бердәм хокукый кырын булдыру мәсьәләләре хакында фикер алыштылар. Очрашуда Татарстанның законнар чыгару инициативалары аерым игътибар үзәгенә алынды. Хәзерге вакытта алар – Думада карап тикшерүдә.

Югарыга омтылыш

Геологиядә – ясалма интеллект, һава чистарту өчен «Ятаган»нар... Хөкүмәт йортында «Татнефтехиминвест-холдинг» җәмгыятенең Директорлар советы утырышы узды. Гадәттәгечә, чарада яңа инновацияле проектлар каралды.

Казан федераль университетының геология һәм нефть-газ технологияләре институты директоры урынбасары Владислав Судаков начарая башлаган нефть запасларын яхшырту өчен яңа геохимик ысуллар уйлап табулары хакында сөйләде. Галимнәр катлаулы ятмаларда нефть чыгаруны арттыруның отышлы ысулларын да әзерли икән. Ә «Татнефть», «Газпром нефть» һәм «Роснефть» нефть ятмаларын эзләү өчен ясалма интеллект технологияләрен сынап карыйлар.

– КФУ базасында геохимик консорциум барлыкка киләчәк. Яңа технологияләрне ил һәм чит ил базарына чыгару мөмкин булачак, – диде КФУ вәкиле.

Бу җәһәттән Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов КФУ һәм ТатНИПИнефть институтына фәнни акылларны берләштерергә тәкъдим итте.

«Ятаган» компанияләр төркеменә нигез салучыларның берсе Валерий Решетняк һава чистарту өчен универсаль системалар турында хисап тотты. Аны нефть химиясендә генә түгел, хәтта авыл хуҗалыгы тармагы, азыктөлек өлкәсендә дә кулланырга мөмкин икән.

Утырышта Татарстанда узачак нефть-газ химиясе форумына әзерлек турында да сүз булды. Моңа өстәп, «TatOilExpo-2023» халыкара күргәзмәсенә әзерләнү турында да сөйләделәр. Татарстанның сәнәгать һәм сәүдә министры Олег Коробченко хәбәр иткәнчә, форум 31 августтан 1 сентябрьгә кадәр «Казан Экспо»да узачак. Чарага федераль статус бирү турында хыялланалар. Быелгы форум республикада сәнәгый нефть табуның 80 еллыгына багышланачак.

ЧҮП ҖЫЙГАНГА – ЮЛЛАМА!

Нәтиҗә

Республикада ике ай дәвамында чистарту икеайлыгы узды.

Шушы вакыт эчендә экологлар 520 мең кубометр чүп җыйса, урманчылар 16 миллион төп агач утырткан. Чистарту өмәләрендә 700 меңгә якын кеше катнашкан. Бу хакта Министрлар Кабинетында узган брифингта сөйләделәр.

– Ике ай эчендә өмәләрдә барлыгы җиде йөз меңгә якын кеше катнашты. Полигоннарга 520 мең кубометр чүп чыгарылды. Яшелләндерү буенча да актив эш бара. Республика районнарында 650 мең төп агач һәм куак утыртылды, – ди Татарстанның экология һәм табигый ресурслар министры Александр Шадриков.

Ике ай буена эшләнелгән эшләргә Татарстанның экология һәм табигый ресурслар министры урынбасары әйләнә-тирәне саклау буенча республиканың баш дәүләт инспекторы Илнур Гобәйдуллин хисап тотты. Кар катламы бетүгә, җиргә бөтен «байлык» чыккан иде бит, ди ул.

– Безнең максат – тирә-якны чүп-чардан арындыру һәм халыкта экологиягә карата уңай караш тәрбияләү. Соңгы елларда табигать сагында торучылар саны арта. Моның шулай икәне аларның безгә килгән мөрәҗәгатьләреннән дә күренә. Ике ай эчендә министрлыкка 5 меңгә якын кеше төрле хәбәр юллады. Мәктәп укучылары да читтә калмый. Алар «Мәктәп патруле» аша 3,5 мең хәбәр җибәргән, – ди Илнур Гобәйдуллин.

Баш дәүләт инспекторы белдергәнчә, шушы вакыт эчендә 8014 хокук бозу очрагы ачыкланган. Шуларның 6890ы бетерелгән дә инде. 1849 тәртип бозучы административ җаваплылыкка тартылган. Аларга 2,5 миллион сумнан артык штраф салынган.

– 8 меңнән артык хокук бозуларның 70 процентын чүплекләр алып тора. Аларның инде 90 проценты тәртипкә китерелде. Чистарту икеайлыгында Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы да зур эш башкарды. Юллардан 5 мең кубометр каты көнкүреш калдыклары җыелды, – ди Илнур Гобәйдуллин.

Александр Шадриков, табигатьне саклау чаралары ярдәмендә соңгы биш елда экологиягә 58 млрд сумлык зыян салынмыйча калды, ди.

– Бу – республикада яшәүче 2,3 миллион кешенең яшәү шартлары яхшырган дигән сүз. Татарстанда экологиягә уңай караш. Дәүләт тә кайгырта, сәнәгать оешмалары да үзләреннән өлеш кертә. Быелгы чараларга бюджеттан 20 млрд сум бирелсә, оешмалар 32 млрд сум акча бүлеп бирде, – ди Александр Шадриков. – Күп эшләр башкарылды. Халыкның зарларыннан соң «Салават Күпере» торак комплексында һаваның чисталыгын автомат рәвештә ачыклый торган махсус күчмә лаборатория куелды. Бүген республикада 9 шундый лаборатория бар. Аларның һәркайсы экологик хәлне тапшырып тора. Тагын бер көтелгән яңалык: тиздән Самосырово бистәсендәге чүплектәге эшләр тәмамлана. Хәзер чүптән энергия алып булачак. Ул 20–25 ел буена халыкны җылылык белән тәэмин итеп торачак.

Татарстан урманнары ни хәлдә соң? Бу хакта тармак министры Равил Кузюров сөйләде. Аның сүзләренчә, урманчылар да чистарту икеайлыгы кысасында тик тормаган.

– Урман эчләрен, юл буйларын чүп-чардан арындырдык. Ике ай эчендә урман эченә ташланган 74 чүплеккә тап булдык. Тиешсез урынга калдыкларны ташлаучылар арасында Казан, Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт, Яшел Үзән шәһәрләре бар. Әлеге чүплекләрне бетерү эшләре бара, – ди Равил Кузюров. – Урманнарның чисталыгын саклау бик мөһим. Ул бит – тирә-якны янгыннан саклау да. Ел башыннан бүгенгә кадәр 855 термик нокта теркәлгән. Узган ел бу вакытта 237 хәбәр килгән иде. Димәк, бик сак булырга кирәк. Янгын куркынычы югары тору сәбәпле, 22 майдан өч атна урманнарга керү тыела.

Штраф белән генә куркытып буламы соң? Илнур Гобәйдуллин исә, бурычыбыз – штраф салу түгел, ди.

– Халык үзе аңларга тиеш дип уйлыйм. Ничек инде чүбеңне каядыр ташларга була? Табигатьне без кайгыртмасак, кем кайгыртыр?! Чүп үзеннән-үзе очып килми. Аны кемдер ташлый бит! Битараф булмыйк, – ди ул.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

СЕЗ – СҮЗ БЕЛӘН ИЛНЕ ДАНЛАУЧЫЛАР

Казанның «Сәйдәш» мәдәният үзәгендә 26 нчы тапкыр уздырылган «Бәллүр каләм» бәйгесенә йомгак ясалды. Җиңүчеләр арасында «Ватаным Татарстан» газетасы да бар. Без «Мультимедиалы редакция» номинациясендә җиңү яуладык. Ә гран-при – Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов исеменнән автомобиль – «Республика Татарстан» газетасының баш мөхәррире Александр Латышевка бирелде.

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе җитәкчесе Әсгать Сәфәров журналистларны Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов исеменнән тәбрикләде. Ул: «Илдә барган вакыйгалар шартларында һәр журналистларның бурычы – үз һөнәренең абруен саклау», – диде.

– Әлеге бәйге озак еллар уздырылса да, актуальлеген һәм мәгънәсен югалтмый. Журналистларны бүген традицион массакүләм мәгълүмат чараларына гына бәйләп карарга ярамый, – диде Әсгать Сәфәров. – Монда социаль челтәрләр дә, мессенджерлар да – халык фикере кабул ителә торган башка мәйданнар да керә. Бүген һәр кеше төрле җирдән бик күп мәгълүмат ала. Бу шартларда иң мөһим бурыч булып, журналистның, авторның халыкка объектив, дөрес, тулы мәгълүмат бирүе кала. Сезнең сүзгә ышаналар, алга таба да ышанырлар дип өметләнәм, чөнки сез җәмәгать фикерен формалаштырасыз. Бу гадәти булмаган вакытта һәркайсыбызга илдә, дөньяда барган вакыйгалардан хәбәрдар булырга кирәк. Монда ялган мәгълүмат булмаска тиеш. Бу шартларда журналистларның беренче максаты – мәгълүмат кырының куркынычсызлыгын саклау. Тармакның һәр хезмәткәре моны аңлап эшләргә тиеш.

Бәйрәмдә катнашкан Татарстан Премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева исә журналистлар язган, сөйләгән сүзнең зур көчкә ия булуына басым ясады.

– Бәллүр каләм ул – нәзберек, җиңел һәм нечкә, шул ук вакытта очлы да. Нәкъ сүз кебек үк. Сүз кешегә канатлар куярга сәләтле. Һәм сезнең команданың профессиональлеге, һәркайсыгызның тырышлыгы аркасында, әлеге каләм безнең республикага, илгә канатлар куя, данлый. Шәхсән үзем безнең бердәм эшчәнлегебез өчен рәхмәт әйтәсем килә. Сезнең сүзләр ярдәме белән илебез данга төренсен, – диде Ләйлә Фазлыева.

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы оешуга – 20 ел. Аның җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев, бәйгедә җиңүчеләрне тәбрикләп, иң лаеклыларның бүләкләнүен әйтте.

Бәйрәмнең төп бүләге – «Лада Гранта» машинасы белән бүләкләнгән Александр Латышев та хисләрен яшереп кала алмады. Редакцияне озак еллар җитәкләгән тәҗрибәле журналистны хезмәттәшләре алкышларга күмде.

– Быел безнең яшь хәбәрчебез федераль Сабан туен яктыртырга барды. Һәм анда көрәштә батыр калган егет өченче ел рәттән федераль Сабан туенда җиңүен һәм ел да «Лада Гранта» белән бүләкләнүен әйткән. Минем мондый бүләкләр алуда тәҗрибәм зур түгел, ләкин мин сезнең барлык мәгънәдә дә көрәш кагыйдәләрен өйрәнүегезне телим, – диде гран-при иясе.

Зөһрә САДЫЙКОВА

«Татар-информ»

Тантанада «Ватаным Татарстан» газетасы баш мөхәрриренең беренче урынбасары Илнар Хөснуллинга «Татарстан Республикасының атказанган матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр хезмәткәре» мактаулы исеме бирелде. Хезмәттәшебезне ихластан котлыйбыз һәм алда да эшендә уңышлар телибез.

Теманың дәвамы 4 нче биттә >

АННАН ҮРНӘК АЛЫГЫЗ!

1 ИЮНЬ – БАЛАЛАРНЫ ЯКЛАУ КӨНЕ

Талантлы балаларга карап сокланмый мөмкин түгел. Кемдер кечкенәдән үк укый-яза белсә, кемдер акча саный, мәктәп яшеннән үк үз бизнесын булдырган. Сәләтләре иртә ачылып, түгәрәктән түгәрәккә йөргән сабыйлар балачактан мәхрүм калмыймы соң? Без 1 июнь – Балаларны яклау көне уңаеннан үзенчәлекле балаларны барладык.

Әминә МОРТАЗИНА, 10 яшь (Казан шәһәре)

Әминә Казандагы 16 нчы инглиз-татар мәктәбенең 4 нче сыйныфын тәмамлаган. 4 яшьтән «Су анасы» шигырен яттан сөйли. Бакчадан ук җырлый. «Шаян ТВ» каналында тапшырулар алып бара. Вәһапов исемендәге, «Сәйлән» фестивальләрендә, «Үзгәреш җиле»ндә катнашкан. «Хәситә» киносында төп рольне башкарган. Музыка мәктәбендә белем ала. Өченче ел инде – «Чулпан» мәдәният үзәге солисты. Медицина белән дә кызыксына. «Тело человека» дигән китаптан конспектлар күчереп язарга ярата икән. Аңа махсус казналык сатып алганнар. Шунда тешләр куя, протезлар ясый. Теләге – теш табибы булу.

Әнисе Гөлнарага: «Әминә уйнарга өлгерәме соң ул?» – дип еш язалар икән.

– Балачагын урламыйм. Бөтен нәрсәне аның белән киңәшләшеп эшлим. «Арымыйсыңмы, ял итәргә вакытың калырмы?» – дип сорыйм. Аның бөтен яклап үзен сынап карыйсы килә. Уенын да уйный, ял да итә белә», – ди җырчы Гөлнара Габидуллина.

Мәрьям МУСТАЕВА, 3 яшь, Баулы районы Татар Томбарлысы авылының иң кечкенә китап укучысы

Ике яшьлек чагында ук Мәрьям китап укымыйча йокларга ятмаган. Хәзер дә шулай. Әнисе Зөлфиягә, китапханәгә барыйк, дип кенә тора икән. Дүрт бала тәрбияләүче ана үзе дә китап укырга ярата, балаларына да шуны сеңдергән. Китапханәгә дә, китап кибетенә дә бергә йөриләр. Ай саен берничә китап сатып алырга тырышалар. Өйдәге китапханәдә Мәрьямнең үз бүлеге бар. Мәрьямне китапханәдә «Авылның иң яшь китап укучысы» буларак бүләкләгәннәр. Китапларны үзе сайлый икән. Кызчык хәрефләрне белә. Тиздән укып та китәр әле.

Семен ИШЕЕВ, бизнесмен укучы:

– Лаеш районының Нармонка авылында яшим. Рождествено мәктәбенең 9 нчы сыйныфын тәмамладым. Куяннар үрчетеп, 10–15 мең сум акча эшлим. Әлеге бизнеска 12 яшьтә үк тотындым. Башта өч баш булса, хәзер 50не асрыйм. Кайчак 100гә дә җитканлә. Табышы бар. Интернет-кибетләрдә сатам. Ике айлык куянның бәясе – 1 мең сум. Акчаны үз кирәк-ярагыма тотам. «Озын колак»ларны карарга көнгә ике сәгать вакыт китә. Моннан тыш, спорт белән шөгыльләнәм.

Александр КУРЕНЕНКО, 14 яшь (Казан шәһәре)

Александр Казандагы сәләтле балаларны олимпиадаларга әзерләү махсус үзәгендә (СОлНЦе) 9 нчы сыйныфны тәмамлаган. Башка сыйныфташларына караганда ике яшькә кечерәк ул. Ни өчен дигәндә, 3–4 сыйныфны экстернат формасында тәмамлаган. Александр – биология, экологиядән узган республика бәйгеләре призеры, Лобачевский исемендәге конференция лауреаты. Музыка мәктәбен тәмамлаган. Мәктәптә кече сыйныф укучыларына биологиядән түгәрәкләр алып бара. Укуын 10 нчы сыйныфта дәвам иттерачәк.

Саша ике яшьтә әти-әнисе сөйләгән барлык әкиятләрне яттан белгән. Хәтере бик яхшы. 3 яшьтә укырга өйрәнгән. Белмәгәне юк. Өендә аны «Кечкенә профессор» дип йөртәләр. Үзен дахига санамый.

– Бүген әти-әниләр хәтта 1 яшьтән үк сабыйларын төрле мәйданчыкларга йөртә башлый. Кая ашыгырга? Мин шаккатам андыйларга. Балаларның балачагы югалмасын. Улым вакытын дөрес бүлә. Дуслары белән аралашырга да вакыты кала. Музыка уен коралларында уйный. Әле менә «Сириус» үзәгеннән биологиядән онлайн курслар алырга әзерләнә. Җәйге көне физика-математика юнәлешендәге «Квант» лагерена барачак, – ди әнисе Анна.

Ислам ӘСХӘДУЛЛИН, Пыжмара мәктәбенең 9 нчы сыйныф укучысы:

– 4 яшемнән сәхнәдә чыгыш ясыйм. Балтач сәнгать мәктәбендә баян һәм вокал белгечлекләре буенча белем алдым. «Балтач кызы, егете» бәйгесендә – гран-при иясе, Римма Ибраһимова исемендәге бәйге лауреаты. Узган ел JuniorSkills-2022 һөнәри осталык бәйгесендә кирпеч салу, машина белән сыер саву операторы, пешерү юнәлешләрендә чыгыш ясадым. Татар халык ашлары компетенциясендә җиңеп, «Алдынгылар» слетында депутатларга гөбадия ясау үрнәген күрсәттем.

Үсмерләр арасында узган «Алло, без талантлар эзлибез» дигән бәйгедә катнашып, сертификат белән бүләкләндем. Алабуга мәдәният һәм сәнгать көллиятенә сынауларсыз керәчәкмен.

Махсус хәрби операциядә катнашучы егетләргә учак ягу өчен чимал әзерлим. Солдатларга ризык әзерләргә, җылынырга мөмкинлек булсын дип тырышам. Кирәк-яракны җәй көннәрендә Сабан туенда сеңлем белән баллы мамык, попкорн сатып эшләгән акчага алам.

Сәрия МИФТАХОВА әзерләде

Мәдәният дөньясында

Николай Михайлов

Мамадышта тумагач…

Бу көнне, ник Мамадышта тумаганмындыр, дигән фикерне шактый ишетергә туры килде. Якташлар гына түгел, килгән барлык тамашачы Мамадыш үзешчәннәренә, аның кул эше осталарына, уңган-булган халкына сокланды. Берәүләр ияреп биеде, икенчеләр баянчыларга кушылып, җыр сузды, өченчеләр исә тыныч кына күзәтте. Казанның Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе концертлар залының тирә-ягы гөрләде. Берничә сәгатькә Мамадыш Казанга күченеп торды.

Республикада «Татарстанның мәдәни башкаласы» бәйгесе дәвам итә. Ул Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы уңаеннан уздырыла. Бәйге 31 марттан 24 ноябрьгә кадәр дәвам итачәк. Җиңгән район 3 миллион сумлык сертификатка ия булачак. Әлеге акча алга таба мәдәни проектларны үстерү өчен тотылачак.

Бәйрәм исе бөтен җиргә таралган иде. Ул көнне Филармония бакчасы да Мамадышның бер урамына әйләнде. Бәйгегә килүчеләр халыкны урамнан ук гаҗәпләндерергә уйлаган. Тамаша кылырга килүчеләр дә, узып кына китүчеләр дә рәхәтләнеп ял итте.

– Мамадыш халкын бик хөрмәт итәм. Әле менә уйлап йөрим, ник Мамадышта тумадык икән, дим. Залга үтмәгән әле, инде урамда күргән матурлык, ишеткән җыр-моң күңелне кузгатты. Эш атнасыннан соң бар арыганнар бетте. Ни дисәң дә, җыр-моң кешене яшәтә, авыруларын онытырга ярдәм итә, – ди Казанда яшәүче Нурания Сафина. – Мине монда берәү дә чакырмады. Үзем килдем. Яшь чакта Түбән Ушма авылыннан бер кыз белән дус идек. Ул хәзер мәрхүм инде. Резедәмне сагыну монда китерде.

Яшьлегем эзләп килүчеләр дә бар иде. Мөршидә апа Җиһангирова гомеренең иң матур елларын Мамадышта уздыра. Югары уку йортын тәмамлагач, юллама белән килеп әләгә ул монда.

– Яратып эшләдем. Җитәкчеләр дә хөрмәт итте үземне. 20 елым ул якларда узды. Аннан соң иремне башка эшкә күчерәчәк, китәргә туры килде. Үзем Арчаныкы булсам да, Мамадыш дип яшим, – ди ул.

Кул эшләре сатучылар янына Казан халкы күп җыелган иде. Берәүләр йон оекбаш сатып ала, икенчеләр чигүле мендәр тышына чират тора. Түбән Сөн авылында гомер итүче Зөбәйдә Гайнуллина исә үзе чиккән кул эшләрен алып килгән. Анда ни генә юк. Культаулыктан башлап зур сөлгегә кадәр бар.

– Йөрәк җылымны кушканга, кул эшләремне яраталар. Кешегә ошагач, эшлисе генә килеп тора, – ди ул.

Биеп-җырлап арыгач, залга узабыз. Анда исә алма төшәр урын да юк! Бу тамаша гына түгел, залда бәйгегә бәя бирүче жюри әгъзалары да утырды. Әлеге чараны Татарстанның мәдәният министры урынбасары Ленар Хәкимҗанов ачып җибәрде.

– Моннан унбиш ел элек Камал театры бинасында бик матур тамаша караганым истә. Шулкадәр матур оештырылган иде ул. Ул чакта да сәхнәдә мамадышлылар иде. Бу чыгышыгыз да тамашачы күңелендә озак саклансын, – диде ул.

Чынлап та, бик матур тамаша карадык. Ике сәгать дәвамында районыбыз мәдәни, милли традицияләрне, гореф-гадәтләрне, йолаларны күрсәтә алдылар. Мамадыш татар, рус, керәшен, мари, удмурт халкы дус-тату яши. Бергәләп барлык бәйрәмнәрне уздыралар. Казан сәхнәсендә дә һәр милләт үз йоласын күрсәтте. Килен төшерү, мендәр тутыру, кыз сорау, балага исем кушу кебек йолаларны күрдек. Әлеге чара җыр һәм бию белән бергә үрелеп барды. Ана белән бала мәхәббәте, буыннар чылбыры, хөрмәт, ярату кебек сыйфатларны да тамаша кылып күрсәттеләр. Район мәдәният йорты җитәкчесе Степан Спиридонов исә, тамаша сценарием бар коллектив белән бергә төзедек, ди. Күңел җылысы кушылганы да сизелеп тора.

Чарага 420 кеше килгән.

– Залда утыручыларның күбесе – якташларыбыз. Сагынып, яратып килүегез өчен рәхмәт сезгә. Мамадыш елдан-ел үзгәрә, матурлана. Дәүләт программалары ярдәмендә кечкенә генә шәһәребездә зур эшләр башкарыла. Туган якларга еш ук кайтыгыз. Безнең ишекләр һәрвакыт ачык, – диде район башлыгы Анатолий Иванов.

Мамадыш халкын Дәүләт Думасы депутаты Рөстәм Кәлимуллин да котлады.

– Күп еллар районны җитәкләргә туры килде. Мамадыш – күңелләрне иң якын торган як ул. Берәү дә аннан үз теләге белән эштән китми. Мин дә үзем теләп китмәдем. Әмма кайда булсам да, сезнең белән горурланып яшим. Теләүче элек Мамадыш өязенә кергән бит ул. Димәк, мин дә – сезнең егет, – диде ул.

Иң зур бәяне тамашачы бирде. Халык җанлы музыкага сусаган икән. Аягүрә басып алкышладылар. Берәү дә кайтып китәргә ашыкмады. Бәйге зур матур очрашу кичәсенә әйләнде. Күп еллар күрешмәгән якташлар табышты. Сөйләшеп сүзләр бетмәде. Бер кичкә булса да, туган якның җылысын тойдык. Рәхәт хисләр белән таралыштык. Кайда гына булса да, кайда гына йөрсә дә, туган ягы кирәк кешегә!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Фильмнарның тәрбияви функциясе турында оныттык кебек. Режиссер Илдар Матуров әнә шундый фикердә. Шуңа һәм яшь буынның геройларыбыз турында берни белмәвенә борчылып, патриотик рухтагы фильм төшергән ул. «Мәдәни инициативалар буенча Президент фонды» белән Татарстанның Мәгариф һәм фән министрлыгы ярдәмендә төшерелгән кинокартина нәрсә турында?

ЯШЬЛӘР ТЕЛЕНДӘ СӨЙЛӘШҮ

«ХӘТЕРЛИБЕЗ ҺӘМ ГОРУРЛАНЫБЫЗ» ФИЛЬМЫН КЕМГӘ КАРАРГА КИРӘК?

:: Илдар әфәнде, әлеге фильм «Безнең тарих – безнең горурлык» проекты кысасында төшерелгән. Аның турында сөйләгез әле. Әлеге проект нидән гыйбарәт?

– Ул өч этаптан тора. Беренчесе – «Хәтерлибез һәм горурланабыз» («Помним и гордимся») документаль фильмын төшерү, икенчесе – әлеге фильмны белем бирү оешмаларында, аерым алганда, мәктәпләрдә күрсәтү. Ахырдан исә шушы кинокартина буенча тест-сораштыру уздырып, нәтиҗәләр чыгару да планлаштырыла. Мондый сораштыруларны берничә мәктәптә уздырырга өлгердек инде.

:: Укучыларга ошыймы соң?

– Караганнары бик ошата. Аеруча скринлайф ысулын кулланып төшерүгә өлешләре ошый аларга. Дөресен әйткәндә, без алдан ук җитди, әһәмиятле темага караган фильмны яшьләргә аңлаешлы телдә һәм аларга ошый торган ысуллар файдаланып төшерүне максат итеп куйган идек. Һәм бу максатка ирештек кебек. Очрашу тәмамлангач, яныма килеп, сораулар бирүчеләр дә булды. Ә бу – соңгы арада бик сирәк күренеш.

:: Бу заманча ысулга бераздан әйләнеп кайтырбыз. Гомумән, патриотик фильм төшерү теләге кайчан һәм ничек барлыкка килде?

– Бик очраклы булды ул. Улымның компьютерда уйнап утырганына игътибар иттем. Бөек Ватан сугышы турындагы уен иде. Ә анда СССР турында хәтта телгә дә алынмый. Бу миңа, билгеле, ошамады. Һәм мин уйлана башладым: безнең балалар тарихны нәкъ менә шушы компьютер уеннары, комикслар ише чыганаклар аша өйрәнә бит. Күпчелек очракта, алар тарихи дөреслеккә туры килми. Балалар геройларыбыз турында берни белмичә үсә. Мин әкрен-әкрен улыма һәм аның иптәшләренә очучылар, Советлар Союзы геройлары Николай Столяров, Мәгубә Сыртланова турында сөйли башладым. Аларның кызыксынып тыңлауларын күргәч, ни дә булса эшләргә кирәк, дип уйладым.

:: Аңлавымча, фильмның сюжеты да шушы вакыйгаларга нигезләнгән.

– Әйе. Николай Столяров һәм Мәгубә Сыртланова турындагы хикәятләр сюжет сызыгының фоны булып тора. Бүген без ватанпәрвәрлек турында бик еш сөйләшәбез, әмма үрнәк алырдай геройларыбызны балалар белми дә үсә. Нәкъ менә аларның образлары аша балалар күңелендә яхшыга, камиллеккә омтылыш тәрбияләп була. Гомумән, патриотизм тарихи хәтер аша формалаша, дигән фикердә мин. Әгәр кеше үз тарихы белән горурлана икән, аны чын патриот дип атарга була.

Янә кино өлкәсенә әйләнеп кайтсак, бүген без фильмнарның тәрбияви функциясе турында оныттык кебек. Ә бит визуаль сәнгать, визуаль образлар – яшь буын өчен иң кулай һәм отышлы тәрбия чаралары. Без бит үзебез дә – геройлар, сугыш турында кино карап үскән буын. Ләкин без яратып караган фильмнар, дөресрәге, андагы алымнар бүгенге яшьләр өчен кызык түгел.

«Хәтерлибез һәм горурланабыз» фильмында төп рольләрне «Z буыны» вәкилләре, ягъни мәктәп укучылары үзләре үк башкара. Төшерү процессы да күбесенчә мәктәптә узды. Шактый катлаулы булды ул, шуңа да безгә ярдәм иткән Татарстан Мәгариф министрлыгына, Казанның Мәгариф идарәсенә рәхмәтле без.

:: Фильмны төшергән вакытта балаларның үзләре белән киңәшләштегезме?

– Әйе, без махсус фокус-төркемнәр җыйдык, укытучылар һәм белгечләр белән киңәшләштек.

:: Алда әйтелгән заманча ысуллар турында да сөйләсәгез иде.

– Фильмны төшергән вакытта, аны нәкъ менә 11–17 яшьлек үсмерләргә кызыклы итү турында уйландык. Аларга хәзер кадр артындагы текстка, озын-озак эпизодларга корылган фильмнар бөтенләй кызык түгел. «ТикТок» буынына динамика, шәп визуал, тизлек кирәк. Без моны исәпкә алырга тырыштык. Һәм шулай ук чагыштырмача яңа ысул – скринлайф кулландык. Ул фильмда телефон экраны яки компьютер мониторында барган «вакыйга»ларны күрсәтүдән гыйбарәт. Алай гына да түгел, кешенең виртуаль дөньяда үзен ничек тотуын күрсәтеп, аның холык-фигылен дә ачарга була. Балаларыбызның гына түгел, безнең дә бар тормышыбыз шул экраннарга бәйле бит хәзер. Шуңа да без мондый алым отышлы булыр дип уйладык.

Әңгәмәдәш – Лилия ГЫЙМАЗОВА

Соклану

Илдар Мөхәммәтҗанов

Матурлыкка гашыйк йөртүче

Яшел Үзән районының Карашәм авылында яшәүче Рәшит Хәмидуллин җәйге йорт тирәләрен әкият почмагына әйләндергән. Су буенда чәчен тарап утыручы Су анасы, себеркесендә очучы Убырлы карчык, Шүрәле, хат ташучы Печкин, Карлсон, күбәләк, кошлар. Йортны әнә шундый 30дан артык әкият, мультфильм геройлары саклый.

– Мин шушы авылныкы, төп нигезем моннан ерак түгел генә. Ә бу йортны без 2010 елда сатып алдык. Шәһәрдә рәхәтләнеп яшәр өчен бар шартлар булса да, күңел барыбер авылга тартыла, – ди Рәшит абый.

Рәшит абый белән Резидә апа кышларын Яшел Үзән шәһәрендә яши. Җәйләрен исә шушы авылда уздыралар. Умарта тоталар. Бакчада бик күп төрле чәчәкләр үстерү дә – Рәшит абыйның күңеленә хуш килә торган шөгыль. Бакча башында гына, чылтырап, чишмәсе дә ага.

– Мин чәчәк ата торган үсемлекләрне яратам. Әни дә чәчәкләр үстерергә ярата иде. Балалар, оныклар кайтуга да йорт тирәләре матур булсын дип тырышам. Кызганыч, чәчәк аткан вакытта килмәдегез. Ул көннәрдә бөтенләй матур була, – диде ул.

Ә төрле сыннар ясый башлавы уйламаганда, кинәт кенә була аның.

– Мин 36 ел буе машина йөртүче булып эшләдем, – ди Рәшит абый. – Пенсиягә чыккач, хыялларымны тормышка ашырып яшәргә булдым. Тәтеш районында апам тора. Минекеләргә охшаш сыннарны беренче тапкыр аларда узган чишмә бәйрәмендә күреп кайткан идем, кызыгып киттем. Аңа кадәр ясап караганым булмады. Шуннан соң акрынлап үзем дә ясый башладым. Авыл халкы башта аңлап бетермәде. «Кыланалар инде», «килешмәгәнне» дип әйтүчеләр дә булды. Тора-бара ияләштеләр, карарга килә башладылар. Ел саен район күләмендә узган бәйгедә катнашабыз, җиде тапкыр беренче урын алдык.

Сыннарны ясар өчен кирәк-яракны махсус эзләп йөрми ул, кул астында булганнарны гына файдалана. Агач, пластик һәм пыяла шешәләр, баллон, пенопласт, ташларны кулланып, кышын Яшел Үзәндәге йортларында төрле сыннар иҗат итә. Шуңа күрә йорт тирәләре ел саен яңа әкият героена байый икән.

– Сыннарның барысын да кышка җыеп, сарайга кертеп урнаштырабыз да майда кабат чыгарабыз. Җәй буе кеше өзелми моннан. Авылга кунакка кайтучылар да, күрше авыллардан да киләләр. Балаларга аеруча кызык, – ди Рәшит абый.

Хатыны Резидә апа исә иренең эшләгән эшеннән тәм һәм ямь табып яшәвенә бик канәгать.

– Рәшит белән яшәү бик рәхәт. Мин үзем – чәчәкләр дөньясыннан ерак кеше. Андый сәләтем юк. Иремнең мондый шөгыле барлыкка килгәч тә сөендем генә. Без бер-беребезне тулыландырып яшибез. Мин – кухняда, ул – бакчада, ишегалдында. Аның кулы җиңел, шифалы. Нәрсә утыртса, шул уңа. Бер-беребезгә каты итеп «син» дип тә әйткәнебез юк, аңлашып яшибез, – ди Резидә апа.

Менә шулай, эчке матурлыкларын башкалар белән бүлешеп яшәүдән тәм табучы Хәмидуллиннар гаиләсенә сокланып кайттык.

Зөһрә САДЫЙКОВА

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, әтисе

ПИСЛИГИН Олег Викторович

вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Документлар идарәсе делопроизводство бүлеге җитәкчесе Матвеева Юлия Олеговнаның авыр кайгысын уртаклаша.

«БӘЛЛҮР КАЛӘМ» – 2023

ТАТАРСТАН ЖУРНАЛИСТЛАРЫ БӘЙГЕСЕНДӘ ҖИҢҮЧЕЛӘР

«ЕЛ МЕДИАПЕРСОНАСЫ»

Александр Шадриков,
Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры

«ЖУРНАЛИСТИКАГА ТУГРЫЛЫК»

Вакыйф НУРИЕВ
(«Казан утлары» журналы)

Рузилә ХӘСӘНОВА
(«Актаныш-информ» мәгълүмат үзәге)

«МУЛЬТИМЕДИАЛЫ РЕДАКЦИЯ»
«Ватаным Татарстан» газетасы
«Татарстан-24» телеканалы

«НӘТИҖӘЛЕ МАТБУГАТ ХЕЗМӘТЕ»
Түбән Кама муниципаль районы матбугат хезмәте

«ҺӨНӘРЕНДӘ ИҢ ЯХШЫСЫ»

Зөфәр ДӘҮЛӘТШИН
(«Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе)

Зилә МӨБАРӘКШИНА
(«Татар-информ» мәгълүмат агентлыгы)

ГРАН-ПРИ
Александр ЛАТЫШЕВ,
«Республика Татарстан» газетасының баш мөхәррире

«ЕЛ ФОТОРЕПОРТЕРЫ»

Михаил ЗАХАРОВ
(«Татар-информ» мәгълүмат агентлыгы)

«ЕЛ ТЕЛЕОПЕРАТОРЫ»

Андрей КЛЮЧНИКОВ
(«Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе)

«ТУГАН ТЕЛ»

Фәнил МУСИН
(Мари Эл Республикасының «Якташлар» газетасы)

«ИҢ ЯХШЫ РАЙОН (ШӘҺӘР) РЕДАКЦИЯСЕ»
«Шәһри Казан-Язмыш» газетасы
«Сарман» газетасы

«ПОПУЛЯР БЛОГЕР»

Илназ ГАБИДУЛЛИН

Алия МӘҺДИЕВА

МАХСУС НОМИНАЦИЯЛӘР

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ИЛКҮЛӘМ ПРОЕКТЛАРНЫ ЯКТЫРТУ БУЕНЧА ИҢ ЯХШЫ МАССАКҮЛӘМ МӘГЪЛҮМАТ ЧАРАСЫ РЕДАКЦИЯСЕ»
«Дружба» газетасы (Нурлат районы)
«Авангард» газетасы (Тәтеш районы)

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ЦИФРЛАШТЫРУ ЕЛЫН ИҢ ЯХШЫ ЯКТЫРТУ»
«Комсомольская правда» газетасы
«Республика Татарстан» газетасы

«РОССИЯ ХАЛЫКЛАРЫНЫҢ МӘДӘНИ МИРАСЫ ЕЛЫН ИҢ ЯХШЫ ЯКТЫРТУ»
«Болгар радиосы»
«Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясе

ТМТВ – 2023: ҖЫРЧЫ, БЛОГЕР, СПОРТЧЫ – БАР ДА БЕРГӘ!

Музыкаль вакыйга

ТМТВ татар музыкаль телеканалы премиясен тапшыру тантанасы быел «Пирамида» концертлар залында үтте. Тамаша, күркәм гадәткә әйләнеп, быел сигезенче тапкыр оештырылды. Елның көтеп алынган мәдәни вакыйгасының быелгы үзенчәлеге нәрсәдә?

Кызыл келәм

Тамаша башланганчы, җырчылар, блогерлар һәм хәтта «Рубин» футболчысы Ленар Фәттахов, УНИКС баскетбол командасы уенчысы Иван Лазарев та традицион кызыл келәмнән узды. Артистлар үз киемнәре, гадәти булмаган чыгышлары белән шаккатырырга тырышты. Беренчеләрдән булып кызыл келәмгә ат җиккән карета килеп туктады. Ул автор-башкаручы Фирүзә булып чыкты. «Принцесса булу балачак хыялым иде һәм бүген, бер мизгелгә булса да, аны тормышка ашыра алдым», – диде ул.

Артистлар күбесенчә стилистлар белән әзерләнгән, әмма кайберәүләр образны тулысынча үзләре, үз зәвыгына туры китереп ясаткан булса кирәк. Әйтик, Татарстанның атказанган артисты Гөлназ Сәфәрова яисә танылган җырчы Дилә Нигъмәтуллина яшьләрчә, заманча киенгән. «Кызыл келәмгә эт белән чыгу идеясе барлыкка килгәч, мин шушы кыю образны күзалладым. Аны үзем интернетта, дизайнерлар арасында да эзләдем. Гомумән, бу образ – эчке халәтемнем бер ягы», – диде ул.

Стиль дигәндә, Гүзәлем һәм Салават Миңнехановлар турында да әйтеп үтми булмас. Алар бер төстә киенеп, быел да кызлары Мәдинә белән бергә тантана кунаклары булды. Шушы зәвыклы гаилә белән бергә әхлаклы мода өлкәсендәге эксперт Җәннәт Минһаҗева да кызыл келәмнән узды.

Яшьләргә – юл!

ТМТВ премиясендә һаман да яңа исемнәр яңгырый. Тамашачы да шуңа ияләшә бара сыман. «Яңа йолдыз» җиңүчеләреннән тыш, биредә әле Нефтекамск егете Лев Кулушев, Элина Әхмәдуллина, автор-башкаручы Илгиз Шәйхразиев белән дуэт җырлаган 12 яшьлек Җәмилә Әсәдуллина, Альберт Вәлиуллин дигән яшь талантларның тавышы яңгырады. Күбесенең премиядә тәүге катнашулары.

Премия тапшыру тантанасының баш режиссеры Алмаз Гыйльметдинов быелгысы турында менә нәрсә ди:

– Безнең компания ел дәвамында татар мәдәнияте өчен күп әһәмиятле чаралар үткәрә. Әлеге премия шулай ук яшь буынга һәм яңа башкаручы артистларга ярдәм итүгә юнәлдерелгән. Шуңа күрә без жанр һәм кыю сәхнә куелышлары белән эксперимент ясарга тырышабыз. Безгә яшьләр өчен татар телендә кызыклы контент ясау мөһим.

Җырчы Гөлназ Асаева әлеге премияне инде өченче тапкыр ала. Ул да бу юлы яшьләрнең күп булуына игътибар итте. «Быелгы ТМТВ премиясенең үзенчәлеге яшь буын җырчыларына үзләрен күрсәтү өчен мөмкинлек бирүдә. Әле генә җырчы карьерасын башлый торган башкаручылар шактый. Аларның шундый зур концертта җырлавы һәм үзләрен күрсәтүе бик мөһим», – диде ул.

Гөлназ шушы тантанага нык әзерләнгәнен дә әйтте. Җырын да җентекләп сайлаган. «Саубуллашу»ны заманында Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова, Хәния Фәрхи җырлаган. «Үземә шундый зур җаваплылык алып, бу җырны башкарырга булдым», – диде Асаева.

Радиодагы яңгыраш

Залда буш урыннар юк иде диярлек. Тамашачы артистларның чыгышларын алкышларга күмде. Әмма, кызганычка, һәр артистның чыгышы халыкны сөендерде дип әйтергә тел әйләнми.

Әлбәттә, югары дәрәҗәдәге башкару сәләтен беркем дә таләп итми. Ә бәлки, кирәктер? Сүз «тере» тавыш белән җырлау турында бара. Татарстанның һәм Башкортстанның атказанган артисты, киң диапазонлы, алтын тавыш иясе Филүс Каһиров белән бер сәхнәгә чыгып, фонограммага җырлаучыларны сизмичә калмыйсың. Тамашачы аны гына аера ала. Артистларның эмоцияләре, хәрәкәте тавышка чыга. Ә менә нәкъ радиодагы кебек яңгыраш уйланырга урын калдыра.

Мәдәни вакыйганың быелгы үзенчәлегенә әйләнеп кайтыйк. Бу хакта танылган дуэт Алсу һәм Азат Фазлыевлар белән сөйләштек. Алар премияне инде алтынчы тапкыр ала.

– Елдан-ел сәхнә бизәлеше үзгәрә, бу бик тә ошый: гел затлы чыгышлар, экраннар, төрле сәхнә куелышлары. Гомумән, бу – бик җитди бәйрәм. Быел әле блогерларны да чакырганнар. Бу инде халыкка тагын да кызыклырак булсын өчендер. Быел тамашачы да икенче төрле: елы шундыймы, бәйрәмеме? Каршы алулары да, кызыл келәм дә – барысы да югары дәрәҗәдә, – диде гаилә дуэты.

Диана КАРПОВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5313 данә
Гомуми тираж – 14266 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 276

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+